**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2015 елның 15 гыйнвары 1№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршында Коррупциягә каршы көрәш буенча комиссия турында нигезләмәне раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2006 елның 04 маендагы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 21 февралендәге «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы көрәш советы турында» ПУ-71 номерлы Әмере нигезендә Әлки муниципаль районы Башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы каршында Коррупциягә каршы көрәш буенча комиссия турында нигезләмәне (1-нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясенең эш регламентын расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе составын яңа редакциядә расларга (3 нче кушымта).
4. Әлки муниципаль районы Башлыгының 2011 елның 1 мартындагы «Нигезләмәне раслау турында»20 номерлы һәм «Әлки муниципаль районы Башлыгының 2013 елның 13 июнендәге 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 63 номерлы карарының үз көчләрен югалтуын таныйрга.
5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы Башлыгы: Ф.М.Дәүләтшин

Әлки муниципаль районы Башлыгының
________________2014 ел, _____ №
карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы каршында Коррупциягә каршы көрәш буенча комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе (алга таба - комиссия) Әлки муниципаль районы башлыгы каршындагы Әлки муниципаль районындагы коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча киңәшмә органы булып тора.

2. Үз эшчәнлегендә Комиссия федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия турында нигезләмә, Комиссиянең эш регламенты һәм аның составы Әлки муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

## II. Комиссиянең төп бурычлары

4. Комиссиянең төп бурычлары:

Әлки муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы көрәш һәм аның нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыру буенча Әлки муниципаль районы Башлыгы тәкъдимнәрен карау һәм әзерләү;

Әлки муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының, граждан җәмгыяте институтларының, оешмалар һәм физик затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (алга таба - коррупциягә каршы көрәш субъектлары);

коррупциягә каршы көрәш чараларын эшләү һәм аларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

коррупциягә каршы көрәш субъектларының тәкъдимнәрен карау һәм аларны гамәлгә ашыру чараларын эшләү;

коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү өчен Әлки муниципаль районы Советына, башлыгына, Башкарма комитетына тәкъдимнәр әзерләү;

коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга коррупциягә каршы көрәш системасын формалаштыру һәм җәмәгать контролен үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

## III. Комиссия вәкаләтләре

5. Комиссия хокуклы:

үз компетенциясе чикләрендә мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең федераль органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан тиешле тәртиптә соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын чакырырга;

коррупциягә каршы тору мәсьәләләре һәм коррупция барлыкка килү өчен шартлар тудыру, аларга билгеләнгән тәртиптә белгечләр һәм галимнәрне җәлеп итеп, эксперт төркемнәре төзү;

Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Әлки муниципаль районы Башлыгына җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыруның торышы һәм нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат бирергә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына коррупциячел күренешләр өчен алшартларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

## IV. Комиссияне төзү һәм аның эшчәнлек тәртибе

6. Комиссия Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасарлары, секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

7. Комиссия рәисе булып Әлки муниципаль районы Башлыгы тора.

Комиссия рәисе булмаганда, аның йөкләмәсе буенча Комиссия утырышын Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

8. Комиссия җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм аларның структур бүлекчәләре, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары җитәкчеләре, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләре, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, югары уку йортлары, коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләреннән төзелә.

Җәмәгатьчелек вәкилләре саны Комиссия составының кимендә өчтән берен тәшкил итәргә тиеш.

9. Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша һәм карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

Комиссия эшен Комиссия рәисе җитәкли.

11. Комиссия утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла.

Комиссия утырышларында көн тәртибен һәм мәсьәләләрне карау тәртибен Комиссия секретаре тәкъдиме буенча комиссия рәисе билгели.

Комиссия утырышларын Комиссия рәисе алып бара.

12. Комиссия эше Комиссия рәисе раслаган еллык план нигезендә төзелә.

13. Комиссия утырышы анда әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашканда хокуклы була.

Комиссия әгъзаларының утырышларында катнашуы мәҗбүри.
Комиссия әгъзасы тарафыннан үз вәкаләтләрен Советта башка затларга бирү рөхсәт ителми.

15. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Утырыш беркетмәсенә комиссия секретаре имза сала һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Комиссиянең утырыш беркетмәләре Интернет челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һичшиксез урнаштырылырга тиеш.

Комиссия карарларын гамәлгә ашыру өчен муниципаль хокукый актлар бастырып чыгарылырга мөмкин.

17. Комиссия эшендә катнашу өчен хокук саклау һәм суд органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

18. Комиссия секретаре:

Комиссия әгъзаларының тәкъдимнәрен гомумиләштерә, алар нигезендә Комиссиянең эш планын әзерли һәм Комиссия утырышларының көн тәртибен Комиссия рәисенә раслауга кертү өчен төзи;

Комиссия утырышлары беркетмәләренең проектларын әзерли, аларны Комиссия рәисенә раслауга тапшыра һәм Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп торуны оештыра;

Комиссия рәисенә коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча комиссия эксперт төркемнәрен төзү, функция һәм составын төзү буенча тәкъдимнәр, шулай ук коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча тикшеренү, эксперт эшләрен уздыруның максатка ярашлы булуы турында тәкъдимнәр кертә.

## V. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү

19. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итү Әлки муниципаль районы Советы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлки муниципаль районы Башлыгының
________________2014 ел, _____ №
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы каршында Коррупциягә каршы көрәш буенча комиссиянең эш РЕГЛАМЕНТЫ**

Әлеге регламент Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе эшчәнлегенең эчке мәсьәләләрен, шул исәптән утырышны алып бару, комиссия әгъзалары арасында эшне бүлү тәртибен билгели.

Әлеге регламентның таләпләре Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе эше өчен мәҗбүри.

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе (алга таба - Комиссия) эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе турындагы нигезләмә, Республика һәм муниципаль коррупциягә каршы программалар, Комиссия эшенең еллык планнары нигезендә оештыра.

## II. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

2.1.Комиссия Әлки муниципаль районы Башлыгы карары белән билгеләнә торган рәис, рәис урынбасары, секретаре, комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

2.2.Комиссия эшен оештыру комиссия рәисенә йөкләнә. Аннан тыш, эшне оештыруда рәис урынбасары, секретаре, комиссия әгъзалары катнаша.

2.2.1. Комиссия рәисе:

Комиссия эшен аның бурычлары нигезендә оештыра;

Комиссия утырышы өчен урынны, вакытны һәм көн тәртибен билгели;

үз урынбасарларына, секретарена һәм Комиссия әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, аларның үтәлешен тикшереп тора.

Комиссия рәисе урынбасары комиссия рәисе булмаганда һәм аның йөкләмәсе буенча Комиссия утырышларын үткәрә.

Комиссия секретаре:

Комиссия утырышларына материаллар, шулай ук аның карарлары проектын әзерләүне оештыра;

Комиссия әгъзаларына чираттагы утырышның урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

2.3.Комиссиянең состав санын Әлки муниципаль районы Башлыгы тарафыннан 7 әгъзадан кимрәк булмаган күләмендә билгеләнә. Комиссия әгъзалары саны комиссиянең эш күләменә карап билгеләнә.

2.4.Комиссия әгъзалары коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру комиссиясе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне караганда тигез хокукларга ия.

2.5 Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда башкаралар.

2.6.Чираттагы утырышның көн тәртибе Комиссия рәисе тарафыннан Әлки муниципаль районындагы коррупциягә каршы тору, шулай ук ачыкланган кисәтүләр һәм хокук бозулар фактлары һәм Комиссия әгъзаларыннан килгән тәкъдимнәр буенча чараларны үтәүгә бәйле гамәлләрне башкаруга бәйле булган материаллар нигезендә төзелә.

2.7.Әзерләнгән материаллар (белешмәләр, мәгълүмат, актлар) утырышка кадәр 5 көн кала секретарьга бирелә, ул алар турында Комиссия рәисе хәбәр итә.

2.8.Комиссия утырышларына хокук саклау органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, җәмәгать һәм коммерция оешмалары вәкилләре, авыл җирлекләре башлыклары, шәхси эшмәкәрләр чакырыла ала.

## III. Материалларны карау тәртибе

3.1.Комиссия утырышлары, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

3.2.Комиссия утырышын Комиссия рәисе (ул булмаганда урынбасары) ача, ул рәислек итүче булып тора.

3.3. Рәислек итүче көн тәртибен игълан итә.

3.4.Рәислек итүче үзе чыгыш ясый яки төркемнең берәр әгъзасына, карала торган көн тәртибен кыскача чагылдыру өчен, сүз бирә, шулай ук әлеге мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр кертә.

3.5.Карала торган мәсьәләнең тәкъдимнәре буенча Комиссия карарлар кабул итә.

3.6.Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашкан комиссия әгъзаларыннан күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.7.Комиссия утырышларында аның әгъзаларының шәхсән булуы мәҗбүри. Алар үз вәкаләтләрен башка затларга тапшырырга хокуксыз. Комиссия әгъзасы утырышта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

## IV. Комиссия актларын рәсмиләштерү тәртибе

4.1.Комиссия утырышын уздырганда утырыш беркетмәсе алып барыла.

4.2.Утырыш беркетмәсе комиссия секретаре тарафыннан алып барыла. Беркетмә рәис тарафыннан раслана (аның юклыгында - урынбасар) һәм секретарь тарафыннан имзалана.

4.3.Комиссия карары игълан ителә һәм рәислек итүче тарафыннан имзалана.

4.4.Комиссия карары өч көн эчендә аларны үтәү өчен җаваплы затларга тапшырылырга яки җибәрелергә тиеш.

4.3.Карарларны вакытында таратуны тикшереп тору Комиссия секретарена йөкләнә.

4.4.Комиссиянең үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кабул ителгән карары дәүләт хакимиятенең барлык органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, юридик затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

## V. Комиссия карары үтәлешен тикшереп тору

5.1.Комиссия карары үтәлешен тикшереп тору Комиссия секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Үтәлеше буенча мәгълүмат Комиссия рәисенә бирелә һәм комиссия утырышларында карала.

Әлки муниципаль районы Башлыгының
________________2014 ел, _____ №
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы көрәш комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| **Дәүләтшин Фердинат Мидхәт улы** | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы, комиссия рәисе; |
| **Никошин Александр Федорович** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| **Куракова Ольга Федоровна** | Әлки муниципаль районы Башлыгының Әлки муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, комиссия секретаре; |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| **Билалов Рәшит Әбрар улы** | Әлки муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| **Камалов Фәнис Флер улы** | Әлки муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе; |
| **Сәлахов Ренас Рәис улы** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары (килешү буенча); |
| **Гарипова Рузия Морат кызы** | **Әлки муниципаль районы Советның юридик бүлеге начальнигы** |
| **Гатауллина Чулпан Ришат кызы** | Әлки муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары; |
| **Хәлиуллин Айдар Ринат улы** | «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы (килешү буенча); |
| **Агапов Андрей Михайлович** | ипаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча); |
| **Петров Владимир Михайлович** | Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча); |
| **Гыйззәтов Руслан Айрат улы** | Татарстан Республикасы Әлки районы прокуроры (килешү буенча); |
| **Ерыганов Сергей Петрович** | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| **Низамиев Азат Рөстәм улы** | «Әлки хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| **Яруллин Әнәс Әһлиулла улы** | «Базарлы Матак РҮХ» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| **Сәгъдиев Әсхәт Минзыятдин улы** | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Әлки муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| **Галләмов Рәис Фоат улы** | Әлки муниципаль районының иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча); |
| **Давлеева Гөлсинә Шәйхетдин кызы** | Әлки муниципаль районы эшмәкәрлек үсеш буенча агентлык рәисе<br>Әлки эшмәкәрлеге буенча<br>муниципаль районга (килешү буенча); |
| **Шакиров Фаиз Вәгыйз улы** | Әлки районы ветераннар-пенсионерлар Советы Рәисе (килешү буенча) |
| **Шәйхетдинов Рөстәм Солтан улы** | «Сугышчан туганлык» иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| **Фәсахов Каюм Минвәли улы** | инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча); |
| **Хәбибуллина Наилә Хәсән кызы** | «Россия пенсионерлары берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Әлки районындагы җирле бүлекчәсе рәисе (килешү буенча); |
| **Смышляева Анастасия Ильинична** | АПК хезмәткәрләре һөнәр берлегенең район комитеты рәисе<br>(килешү буенча). |